**СОВЕТ ТАТАРСКО-САРАЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422633,РТ, Лаишевский район, село Татарские Сарaлы, ул.Татарстан, д.17
тел: 8-(84378) -4-77-49
факс: 8-(84378) -4-77-49

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАТАР САРАЛАНЫ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422633, РТ, Лаеш районы, Татар Сараланы авылы, Татарстан урамы, 17 нчейорт
тел: 8-(84378) -4-77-49
факс: 8-(84378) -4-77-49

**№152** **2019 елнның 7 октябреннән**

# РЕШЕНИЕ
# КАРАР

**"Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Татар Сараланы авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында” Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Татар Сараланы авыл җирлеге Советы карары проекты хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар һәм «Муниципаль берәмлекләр Уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 21.07.2005 ел, №97-ФЗ Федераль законнар, Татарстан Республикасының 28.07.2004 ел, №45-ЗРТ «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Законы нигезендә Татар Сараланы авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Татар Сараланы авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертергә.
2. Әлеге карарны «Камская новь» («Кама ягы») район газетасында, махсус мәгълүмат стендларында һәм интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга (игълан итәргә): http://pravo.tatarstan.ru.
3. Бу карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татар Сараланы авыл җирлеге Советы Рәисе-Башлыгы И. Ф. Мөбәрәкшинга йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы**
**Татар Сараланы авыл җирлеге**
**Башлыгы, Совет рәисе** **Мөбәрәкшин И.Ф**

**Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы**
**Татар Сараланы авыл җирлеге**
**Советының 2019 елның 7 октябрендәге**
**152  номерлы карарына Кушымта**

**“Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Татар Сараланы  авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр”**

23 статьяның 9 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: «9. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясында каралган гражданнар җыены анда әлеге торак пунктта яшәүчеләрнең сайлау хокукына ия булган яртысыннан артыграгы катнашуда вәкаләтле, әлеге Устав нигезендә гражданнар җыены Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Татар  Сараланы авылында гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмә белән расланган тәртиптә гражданнар җыенын үткәрү турында Карар кабул ителгән көннән бер айдан да артмаган вакыт эчендә уздырыла. Шул ук вакытта элек гражданнар җыенында катнашкан затлар тавыш бирүдә киләсе этапларда катнашмый.»

**Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы**
**Татар Сараланы авыл җирлеге**
**Башлыгы, Совет рәисе** **Мөбәрәкшин И.Ф**